| ГЛАВА<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**07.04.2017** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 01-03-78** |

Зеленодольск муниципаль районы Советының «2016 ел өчен Зеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү хакында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 28 статьясы һәм Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 15 статьясы, Зеленодольск муниципаль районында ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, ачык тыңлаулар уздыру юлы белән 2016 ел өчен Зеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлеше хисап турында фикер алышуда катнашу өчен Зеленодольск муниципаль районында яшәүчеләрнең хокукларын үтәү максатларында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының «2016 ел өчен Зеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.
2. Билгеләргә:
2.1. үткәрү датасы һәм вакыты - 2017 елның 17 апреле 16.00 сәгатьтә;
2.2. үткәрү вакыты 1 көн;
2.3. үткәрелү урыны - Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 46 йорт, Горький исемендәге мәдәният, сәнгать һәм халык иҗаты үзәге;
2.4. чыгыш ясау хокукы белән заявкалар, фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелә торган адрес, Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41а йорты, 306 нчы кабинет, Зеленодольск муниципаль районы Советы аппараты;
3. Халык алдында тыңлаулар уздыруның инициаторы булып Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы тора.

4. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына:

4.1. Зеленодольск муниципаль районы Советының «2016 ел өчен Зеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында» гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән вакытларда карар проекты буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

4.2. ачык тыңлауларның нәтиҗәләрен 2017 елның 21 апреленнән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга;

4.3. Зеленодольск муниципаль районы Советына ачык тыңлаулар киңәшмәсен, ачык тыңлаулар беркетмәсен, шулай ук ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча йомгаклауны 2016 ел өчен Зеленодольск муниципаль районы бюджетының үтәлеше турындагы хисап белән бер үк вакытта эшләнеп беткән ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмәне кертергә.

5. 2017 елның 10 апрелена кадәр әлеге карарны һәм “2016 ел өчен Зеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында” Зеленодольск муниципаль районы Советы карары проектын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Э.Р. Кадниковага йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы** **А. В. Тыгин**